## Андреева Роза Бадриевна - яраткан укытучы, кадерле әни

*Балаларның теле – кыңгырау,*
*Гел чыңгылдый, ява мең сорау.*
*Барсына да җавап биргәнсез,*
*Сез – иң гүзә кеше икәнсез.*

Халык шагыйре Фәнис Яруллинның “Укытучыма” шигырендәге әлеге юллар Роза Андреевага туры килә. Ул – олы җанлы мөгаллимәләрнең берсе. “Агач җимеше, кеше эше белән билгеле” дип, юкка гына әйтмиләрдер.

Мулланур Вахитов исемендәге 2нче мәктәптә укып, эшләп лаеклы ялга чыккан тыл һәм хезмәт ветераны Роза Бәдри кызы гомерлеккә укучыларның яраткан укытучысы, якын дусты, сердәше булып калды. 2014 елда ул 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Еллар сизелми узса да, Роза Бәдриевна эчкерсезлеген, ихласлыгын, тырышлыгын югалтмый. Юкса, ул үткән тормыш юлы җиңел булмаган.

Гимназия юбилее алдынан ул үзенең гомер йомгагын сүтеп, хатирәләрен яңартты.

Роза Бадриевна Андреева 1929 елның 28 февралендә элеккеге Чаллы районы, хәзерге Тукай районы Түбән Суыксу авылында туган. Роза Бәдриевнага 2 яшь вакытында әтиләре белән Яр Чаллыга күченгәннәр. Ул вакытта балалар бакчалары булмау сәбәпле, Роза Бәдриевна өйдә генә тәрбия алган.

Роза Бәдриевнаны тугызынчы яшендә Мулланур Вахитов исемендәге мәктәпкә укырга биргәннәр. Хәреф танырга, укырга-язарга өйрәткән укытучысы Әсма Хәйдәрованы, мәктәп директоры, математика укыткан Сәлим Әминовны бүген дә сагынып искә ала ул. Тырышлыгы, яхшы укуы, җәмәгать эшләрендә актив катнашуы белән сыйныфташларыннан аерылып торган кызны укытучылар үзләре дә яраткан. Менә ул еллар турында Роза Бәдриевна ничек искә ала:

*“1937 елда Яр Чаллының Мулланур Вахитов исемендәге мәктәбенә 1нче класска укырга кердем. Беренче укытучым Хәйдәрова Асма Хөснулловна иде. Ул безне 4нчые классны тәмамлатып, 5нче класска тапшырды. Ул вакытта башлангыч классның 3нче классыннан рус теленнән башка укытучы укытты – Разия Гариповна. Бу укытучы, ул вакытта башлангыч классларда пионер вожатый да булып эшләде, ә лаклы ялга киткәндә, шул ук мәктәптә тарих укыта иде. Башлангыч класста укыганда класслар арасында ярышлар була иде. Шул ярыш нәтиҗәләрен чыгару өчен класстан бишәр укучыны комиссиягә кертеп, параллель классның уку һәм эш нәтиҗәләрен тикшереп йөри идек. Безнең параллель класста Җиһан апа укыта иде. Ул вакытта мәктәп директоры Әминев Сәлим Гәрәевич иде. Ул*

*безне математикадан укытты, ә аның тормыш иптәше Зәйнәп Хәбибулловна рус теле укытты һәм безнең класс җитәкчесе булды. Безнең мәктәп төрле җиргә таралган иде. Мин үзем беренчедән алып дүртне бетергәнче Ленин урамының Кама елгасы буена урнашкан ике катлы бинада укыдым, ә безнең параллель класс (Центральная) Үзәк урамда бер катлы агач йортта укый иде. Бишенче класска күчкәч, Фрунзе урамындагы агач бинада укып, шунда 10нчы классны тәмамладым. Ул чагында икешәр смена укылды. Мәктәп утын белән ягыла, керосин лампалары белән яктыртыла иде. Суны да техникалар чакыртып җылыталар иде. Мәктәптә укыган чорлар бик авырга туры килде".*

Бөек Ватан сугышы башланганда Роза Бәдриевнага 12 яшь була. Мәктәптә укулар соңрак башлана, бер ай иртә тәмамлана. 2нче мәктәп директоры Нурия Сәхәбиева Тукай районы "Шанхай" совхозы белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзи. Шуның нигезендә җәйдән алып урып-җыю эшләре тәмамланганчы, укучылар совхозда эшли. Кырда чүп үләннәре утыйлар, көлтә бәйлиләр. Бала-чага өчен эш авыр булса да, тамаклары тук булганга сөенеп эшлиләр. Роза Бәдриевна сугыш елларындагы мәктәп тормышы турында:

"*Бишенче класска күчкәч тә, сугыш башланды. Анда кайбер фәннәр укытылмады да. Укытылганнары да белемнәре буенча туры килмәде. Чит ил теле бөтенләй укытылмады, биологиядән башлангыч класс укытучысы Бусыгина Анна Константиновна укытты. Җыр һәм рәсем сәнгатьләре турында әйтеп тә торасы түгел. 6нчы класста комсомолга кердем.*



Яр Чаллы шәһәренең М. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбенең 4нче сыйныф укучылары. 1941 ел, 20 май.

*Сугыш башлангач, мәктәп Красный Ключнең Шанхай совхозы белән договор төзеде. Каникул вакытында 5нче -10нчы класс укучылары шунда эшли идек. Ул вакытта көлтә бәйләп, чүп утап, яшелчәләр үстердек. Мәктәп директоры Сәхәбиева Нурия Усмановна, ул ук баш бригадир да иде. Җыештыручы булып эшләүче  Салиха апа пешекче дә иде. Салиха апа аш, боламык пешереп, аңа аз гына май салып ашата иде. Баш бригадирның ярдәмчеләре булып барлык укытучылар да эшләде: Асанова Оркыя апа, Асма апа, Җиһан апа һ.б.*

*Җәй көнендә югары класс укучылары белән укытучылар урманда утын әзерләргә баралар иде. 4нче-6нчы класс укучылары белән мине калдырып китәләр иде. Иртәнге сәгать дүрттән кичке караңгы төшкәнче эшли идек.*

*Бер елны югары сыйныф укучылары белән мине урманга утын кисәргә җибәрделәр. Мине бригадир итеп куйдылар. Икмәк саклый торган амбарларда яшәп, сугыш беткәнче “Шанхай”совхозында эшләдек. Совхоз директоры Шәйхетдинов абый эшләр тәмамлангач, икешәр капчык бодай, тырышып эшләгән өчен өч литрлы банка бал да бирде. Совхозда эшләр тәмамлангач, Түбән Суыксуда көл, ашар өчен черек бәрәңге җыйдык.*

*Ул вакытта укулар сентябрьдә түгел, ноябрь башында гына башлана иде. Уку әсбаплары (китаплар, дәфтәрләр, ручка, каралар) юк иде. Иске китапларга, газеталарга, корымнан кара ясап яза идек.*

*Ашарга юк вакытлар...*

*7нче-8нче класста укыган вакытта хәрби дәресләр керде. Кызларны сугышка санитарлар итеп җибәрергә әзерләделәр.*



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбенең 8нче сыйныф укучылары хәрби киемнән.1945 ел, 1 май.

*Тормыш авыр булу сәбәпле күп укучылар мәктәпне ташларга мәҗбүр булды. Никадәр генә авыр булмасын, җәмәгать эшләрендә дә катнаштык. Концертлар куеп, спектакльләрдә уйный идек.*



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбенең 9нчы сыйныф укучылары.1946 ел.

*8 нче класстан башлап 10ны бетереп чыкканчы комсомол оешмасы секретаре булдым. Ул вакытларда мәктәп педсоветларында еш катнашырга туры килде. Аннан район конференцияләрендә, пленумнарда катнаштым.*

*Бишенче сыйныфта укыганда 45 бала идек.10нчы классны без 6 укучы гына тәмамладык (1 егетебез – 5 кыз), чөнки Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, авыр еллар башланды. Сигезенчедән соң уку өчен 150 сум түләргә кирәк иде. Моңа бөтен кешенең мөкинлеге булмады. Тырышып укыганга, җәмәгать эшләрендә актив катнашканга миннән түләтмәделәр. Миңа мәктәп бер тапкыр киез итек, метр ярым бәз, резина галош бирде. Бәзне химик карага манып, юбка тегеп кидем, галошлардан туфли ясадым. Класслар салкын, өс киеме, бияләйләр киеп утырдык. Без чыгарылыш класс булгач, безне директор бүлмәсенә тимер мич куеп, шунда укыттылар”.*



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбенең 10нчы сыйныф укучылары. 1947 елның мае.



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге2нче номерлы урта мәктәбенең 10нчы сыйныф укучылары. 1947 ел.

Тормыш авыр булса да, укуга, эшкә дәрт сүнмәгән Роза Бәдриевнада. Урта мәктәптән соң бер ел Яр Чаллыда Пионерлар йортында эшләгәч, 1948 елда Казан дәүләт педагогия институтының биология факультетына укырга керә. Ләкин тормыш авыр булу сәбәпле, анда укый алмый. Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга кадәр барып җиткән апасы Мөнҗия аны үзләре янына Калининград өлкәсенең Советск шәһәренә чакыра.Ләкин анда да яктылык күренми. Апасы, җизнәсе белән май аенда Яр Чаллыга кайткач, 1949 елны Алабугадагы укытучылар әзерли торган институтка укырга керә.



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге2нче номерлы урта мәктәбендә практикада. 1951 ел.

Монда да уку җиңел булмый, авыр тормыш кызны өстендәге пальтосын да сатарга мәҗбүр итә. Тырыш судентны монда да күреп алалар. 1951 елда Алабуга укытучылар институтын тәмамлап,Казан дәүләт педагогия институтына читтән торып укырга керергә җайлы булыр дип, Әтнә урта мәктәбенә эшкә билгелиләр. Тик анда эшләргә насыйп булмый, урынына кеше алганнар икән. Шулай итеп, ул үзенең хезмәт юлын Тукай районының Борды мәктәбендә география, химия укытучысы булып башлап җибәрә. Бер чиләк бәрәңге 400 сум торганда, атнасына 18 сәгать дәрес биргән башлангыч сыйныф укытучысына 605 сум хезмәт хакы түләгәннәр. Математика һәм башка фәннәрне өстәп укыта башлагач, эш хакы 900 сумга җиткән. Бушлай утын, керосин биргәннәр. Укыткан дәверендә Роза Бәдриевна пленум члены булып комсомол эшендә дә актив катнаша.

Дүрт ел эшләгәннән соң, 1955 елда Иван Андреевка кияүгә чыгып, Роза Бәдриевна Пермь өлкәсенең Кизель шәһәренә китә. Башта 4 км ераклыктагы Володарка посёлогында башлангыч сыйныфларда, аннары 6 км ераклыктагы Ленинка посёлогында татар теле укыта. Эшкә җәяү йөри. Шундый авыр шартларда да кешелеклелеген югалтмыйча, балаларга белем бирә. Шуңа да, мөгаллимәне балалары зурлап озатып калалар.

Пермь климаты Роза Бәдриевнаның сәламәтлегенә ярамаганга, Андреевлар гаиләсе 1957 елда Яр Чаллыга кайтып төпләнә. Шәһәр мәктәпләрендә урын булмагач, янәдән Бордыга биология һәм химия укытучысы булып эшкә керә. Ләкин кыскартуга эләгеп, эшсез кала. 1958 елдан 1961 елга кадәр Кама посёлогында башлангыч сыйныф укытучысы булы эшли. Озак та үтми, 1961 елны аны Яр Чаллының 2нче мәктәбенә “озынайтылган көн” төркемен оештырырга җибәрәләр.



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбе укытучылары коллективы. 1972-1973нче уку елы.



Тукай районы һәм Яр Чаллы шәһәренең башлангыч сыйныф укытучыларының белем күтәрү курсларында 1964-1965нче уку елы.



Яр Чаллы шәһәренең М. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбендә укып, шул ук мәктәптә эшләгән укытучылар. 1979 ел, 4 февраль.

Бер ел эшләгәннән соң, Роза Бәдриевнага беренче сыйныфны укытырга бирәләр. Ринат Ибраһимов, Римма Егорова, Гөлүсә Әхтәмова, баянчы Илгизәр Хәбибуллин һәм башкалар классы була ул. Укучылар аны әниләре кебек яраталар, үз итәләр. Бәләкәй буйлы Әлфия (бүгенге көндә Казанда яши) тәнәфескә чакырып кыңгырау шалтырауга, йөгереп килеп укытучы апасының итәгенә менеп утыра торган булган.



Яр Чаллы шәһәренеңМ. Вахитов исемендәге 2 нче номерлы урта мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучылары арасында.1971-1972 нче уку елы.

Беренче сыйныф белән беррәттән  урта буын һәм югары сыйныфларда Роза Бәдриевна биология укыта башлый һәм шул көннән аңа биология кабинетын тапшыралар, биология секциясе җитәкчесе итеп куялар.


Биология дәресендә.


Биология дәресендә.



Биология дәресендә.



Биология түгәрәгендә.

Роза Бәдриевна искә ала:*“Балалар белән түгәрәкләр үткәрдек. Алар белән кабинетны ясадык һәм гөлләр үстердек. Кош оялары ясап, кошларны каршылау бәйрәмнәре үткәрә идек. Олимпиадаларга әзерләнә идек.Укучылар республика олимпиадасында да катнашып, 2нче-3нче урынарны алалар иде.*



Яр Чаллы шәһәренең М. Вахитов исемендәге 2нче номерлы урта мәктәбенең 4нче сыйныф укучыларының отряд җыены.

*Шәһәр урамнарын яшелләндерүдә дә актив катнаштык. ГЭС посёлыгындагы паркны оештыруда төп урынны алдык. Нарат агачларын без утырттык...Үземә 1979 елны врачлар тәкъдиме белән эшне калдырырга туры килде".*

*Роза Бәдриевна лаеклы ялга чыкса да, үзе укыткан укучылары белән тыгыз элемтәдә тора."Бер елны туганнар, балалар белән туган көнемне билгеләп утырганда, ишектә кыңгырау шалтырады. Ишекне ачсам, укучыларым тезелеп басып торалар. Безнең яраткан укытучыбыз, сезне бәйрәмегез белән котлыйбыз, диләр",* - ди Роза Бәдриевна. Ел саен 1972 нче елның чыгарылыш сыйныфы укучылары Роза Бәдриевна янына килеп, табын көйләп, укытучыларына бәйрәм ясыйлар икән.


1972 нче елның чыгарылышукучылары арасында.

Аллага шөкер, балаларыннан да уңды Роза Бәдриевна. Яшьли тол калып, ике баланы берүзе үстерде. Икесе дә урта мәктәпне тәмамлап, берничә югары белемле белгечләр булды. Кызы Флёра кечкенә вакытыннан ук әнисе кебек 1нче мәктәпнең алдынгы һәм актив укучысы иде. Бүгенге көндә ул шәһәр советы рәисе урынбасары булып эшли. Улы Альберт та төрле җаваплы урыннарда эшләде, хәзер әнисенең төп таянычы. Балалары “Оҗмах аналарның аяк астында” дигән гыйбарәгә тугры калып, әниләрен кадер-хөрмәттә яшәтәләр.


Кызы Флёра һәм улы Альберт белән.

Иренең туганнары да хөрмәт итә Роза апаны. Һәр көнне телефоннан шалтыратып, я булмаса өенә килеп хәлен белеп китәләр. Олы җанлы, киң күңелле апаларын алар да ярата.



Яр Чаллы шәһәренең хезмәт ветераннары өчен пансионатта узган
Роза Бәдриевнаның күргәзмәсе. 2011 ел.

Чәчләренә чал керсә дә, Роза Бәдриевна картаерга ашыкмый. Күзләре авыртмаганда костюмнар, күлмәкләр, пальтолар бәйли.Аларны хәтта күргәзмәләргә дә куйганнар.

Менә шулай күпләргә үрнәк булып гомер кичерә мәгариф ветераны Роза Бәдриевна. Киләчәктә дә Аллаһы Тәгалә аны сәламәтлектән аермасын.

P.S.

Роза Бәдриевна:

*“Бу мәктәптә минем ике апам да укыдылар. Аларны да башлангыч класста Асма Хөснулловна укытты.*

*Зур апам Мөнҗия сугышта катнашып, сугыш бетүне Берлинда каршылады. Ул медсестра булып хезмәт итте. Күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнде.*



*Зур апасы –Мөнҗия Мөхәммәтҗанова*



# НАГРАДА НАШЛА ВЕТЕРАНА

## ЕЩЕ ОДИН БОЕВОЙ ОРДЕН МУНЗИИ МУХАМЕДЗЯНОВОЙ

**Мунзия Бадриевна неспеша перелистывала семейный альбом, подаренный мужем ей в день рождения. С любительских выцветших фотографий глядели на нас ее фронтовые друзья из бывшего 16-го танкового корпуса — бакинка Нина Павловна Пташко, Хусниури Хисматуллина и Филипп Иванович Баранов из Казани, Лидия Титовна Кравченко из Белоруссии, просто Алеша — санитар из Сухуми, сибирячка Анна Богатырева...**

По-разному складывались их довоенные судьбы, но июньский день 1941 года разом перечеркнул все планы, мечты. На долгие годы война оторвала от родной семьи студентку I курса Казанского медицинского института М. Мухамедзянову. Поначалу она медсестрой работала в одном из госпиталей Казани, потом, уже в составе бывшего 16-го танкового корпуса, прошла нелегкими дорогами воинов-освободителей от Курска до Берлина.

Десятки городов Украины, Румынии, Польши, ГДР вспоминают в памяти фронтовой медсестры. Для участников Орловско-Курской операции эта битва, наверника, запомнилась неумолкающей артиллерийской канонадой, несмолкаемым потоком танков.

— Тогда у нас в госпитале, — вспоминает Мунзия Бадриевна, — смешались день и ночь. Сутками мы не отходили от операционного стола. Представьте себе, что нас, как маленьких детей, поили чаем, давали что-нибудь перекусить. Сколько крови, человеческих страданий довелось тогда увидеть! Никогда, пока жива, я не забуду.

А память, разбуженная этими лицами из далекого прошлого, застывшими на фотографиях, услужливо подсказывает все новые и новые случаи — и курьезные, и драматические. Как довелось расстаться с красивой косой, когда ее свалил сыпной тиф. Как оставили ее в деревушке со смертельно раненым лейтенантом-разведчиком. Думали, не выдержит он нечеловеческих мук, похоронит его сестричка Муся и пойдет догонять бывший 208-й медсанбат. Ан нет, жизнь распорядилась по-своему. Через десять дней она со спасенным разведчиком вернулась в часть. Как вызвалась лечить и ухаживать за солдатом, который по всем признакам считался больным холерой, а на самом деле получил сильное отравление. Как со слезами доила корову, потому что раненый просил ее за родную мать и просил дать парного молочка. Как попала в аварию, о которой напоминают сейчас больные ноги, и какой веселой была прифронтовая свадьба сестрички Муси и старшего лейтенанта Михаила Сергеевича Фурса, ныне военрука бакинской школы № 14. Как уже в шести километрах от Берлина вместе с тяжело ранеными, оставленными ей для присмотра, готовилась встретить бой с целой колонной немцев, которые, как выяснилось потом, узнав о капитуляции фашистской Германии, шли сдаваться русским. Как... Да мало ли было разных событий и встреч в те далекие сороковые годы, которые и сейчас, почти через сорок лет, приходят во сне с такой ужасающей ясностью и подробностями, словно случилось это по крайней мере вчера.

По моей просьбе Мунзия Бадриевна показывает свои награды: медаль «За боевые заслуги» и орден Красной Звезды. И с особой бережностью протягивает орден Славы третьей степени, который ей только что вручили в республиканском военкомате. Не знала о своей последней боевой награде медсестра Мухамедзянова — была переведена в другую часть. И вот, сейчас, спустя тридцать шесть лет, награда нашла ветерана войны.

Несколько смущаясь от расспросов журналиста, рассказывает о себе Мунзия Бадриевна. Но как ни тяжелы воспоминания, ей еще не раз придется вернуться к тому грозному времени. Потому что хотят знать все о Великой Отечественной войне ребята из 60-й школы Октябрьского района, где она работает медсестрой. Потому что хотят знать не по книгам о войне ее внуки Наташа и Максим. Потому что судьба матери дорога детям Володе, Юре и Лилии, ставшей врачом, как мечтала в юности ее мать медсестра Муся. Потому что священен боевой подвиг простой девушки из Казани.

Мария ТОРБА.

*Мөнҗия Мөхәммәтҗанова турында мәкалә.*



*Мөнҗия Мөхәммәтҗановага бирелгән рәхмәт хатларының берсе.*

*Икенче апам Мөгәллимә Яр Чаллы шәһәренең 9нчы мәктәбендә озынайтылган көн группасы белән эшләп, шуннан пенсиягә чыкты”.*



Беренче рәттә сулдан уңга: Роза Бәдриевнаның энесе Мирза, әтисе Бәдретдин ага, Мөнҗия апасы, Мөнҗия апасының улы Володя, Мөнҗия апасының ире Михаил, Роза Бәдриевнаның кече энесе Фоат;

Икенче рәттә уңнан сулга: Роза Бәдриевна, әнисе Мәрьям апа, кече апасы Мөслимә.

**Мәкаләне Яр Чаллы шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназиянең музыка укытучысы Шәйгәрдәнова Ләйсән Зөфәр кызы әзерләде.**